| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» 02 2022 ел № 70

2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы, «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1.1. гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

а) ялгыз яшәүче граждан өчен: 87552,75 сум;

б) ике кешедән торган гаиләгә: гаиләнең һәр әгъзасына 55715,38 сум;

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә: гаиләнең һәр әгъзасына 47756,04 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 3171564 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 4036536 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 5189832 сум;

1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 6919776 сум;

1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 8649720 сум;

1.2.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 10379664 сум;

1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 12109608 сум;

1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен - 13839552 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе — А. Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2022 елның _______________
___70___ номерлы карарына
кушымта

**2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. Найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,
биредә:
СЖ - исәп-хисап күрсәткече;
НП - муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - торак урынның муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган, Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе (2022 елның беренче кварталына – 96 108 сум).
а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 96108 х 33 = 3171564 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 42 = 4036536 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 18 х 3 = 5189832 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 18 х 4 = 6919776 сум
д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 18 х 5 = 8649720 сум
е) алты кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 18 х 6 = 10379664 сум
ж) җиде кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 18 х 7 = 12109608 сум
3) сигез кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 96108 х 18 х 8 = 13839552 сум.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәп-хисап күрсәткеченә тигез дип кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле булган, гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС),**

биредә:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы елына 8,5%, ягъни 8,5/100/12 айга=0,0071 айга);

КП - кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 96 мең 108 сум күләмендә билгеләнгән.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү**

1 нче таблица

| НП - торак урынның нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак бинаның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы | ПД - керемнең максималь күрсәткече (сум). (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 96108 | 8,5/100/12= 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,25 | |
| 33 | 3171564 | 1 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,25 | 87552,75 |
| 42 | 4036536 | 2 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,5 | 55715,38 |
| 54 | 5189832 | 3 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,75 | 47756,04 |
| 72 | 6919776 | 4 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1 | 47756,04 |
| 90 | 8649720 | 5 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,25 | 47756,04 |
| 108 | 10379664 | 6 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,5 | 47756,04 |
| 126 | 12109608 | 7 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,75 | 47756,04 |
| 144 | 13839552 | 8 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 2 | 47756,04 |